ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 121 «_22_» _11_____ 2017 ел

Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен
түләү буенча авыл җирлегендә эшләүче
һәм яшәүче аерым категория гражданнарга
социаль ярдәм чаралары турында «Мамадыш
муниципаль районы Башлыгының 22.12.2006 ел,
№ 056 карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

Авыл җирлегендә эшләүче һәм Яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә  к а р а р  б и р ә м:

1. Мамадыш муниципаль районы башлыгының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 22 декабрендәге 056 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә:

Түбәндәге эчтәлекле 1.1., 1.2 пунктларын өстәргә:

«1.1 Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын тәкъдим итүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

1.2 Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнар категорияләренә социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат ЕГИССО Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә ЕГИССО куллану юлы белән алынырга мөмкин.".

1. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе И.Э. Фәттаховка йөкләргә.

муниципаль район
Башлыгы А.П.Иванов